ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ СӘЙТӘК ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

20 ноябрь 2024 ел № 4

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең
Сәйтәк торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 9 ноябрендәге 9 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылы гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан бер тапкыр түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Сәйтәк авылындагы юлларны кардан чистарту, вак таш сатып алу, Сәйтәк авылына илтеп җиткерү, тигезләү).
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (кое һәм янгын гидранты урнаштыру)

3. Әлеге карарны Бәзәкә авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов